КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 3 март г.Казань № 205

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 23 декабрь, 1052 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 23 декабрь, 1052 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 февраль, 128 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 860 нчы; 2015 ел, 26 август, 623 нче; 2016 ел, 17 октябрь, 749 нчы; 2016 ел, 31 октябрь, 800 нче; 2017 ел, 10 май, 269 нчы; 2018 ел, 30 июль, 613 нче; 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче; 2018 ел, 19 декабрь, 1179 нчы; 2018 ел, 29 декабрь, 1302 нче; 2019 ел, 13 июль, 577 нче; 2019 ел, 19 ноябрь, 1057 нче; 2020 ел, 6 март, 178 нче; 2020 ел, 19 май, 405 нче; 2020 ел, 2 июнь, 458 нче; 2021 ел, 10 апрель, 238 нче; 2022 ел, 10 май, 427 нче; 2022 ел, 5 декабрь, 1281 нче; 2023 ел, 25 гыйнвар, 40 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

1.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.9. Министрлыкның урнашу урыны: 420012, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Бутлеров урамы, 40/11 нче йорт.»;

3.3 пунктның 3.3.47 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.47. Юридик затларның документларын карап тикшерү һәм сәламәтлек саклау объектларының, Министрлык эшчәнлеге өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган масштаблы инвестиция проектларының Татарстан Республикасы Җир кодексының кушымтасында билгеләнгән критерийларга туры килүе турындагы бәяләмәләр проектларын килештерү.»;

4.1 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин